Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районы

Масловка авыл җирлеге Советы

**КАРАР № Х**

Масловка ав. 2020 елның 02.11.

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советының 2017 елның 04.09. №11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл жирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл жирлеге Советы карары проекты хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, “Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җитештерү һәм куллану калдыклары турында” 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон, “Каты коммуналь калдыклар белән эш итү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 25 августындагы 641 номерлы карарына үзгәреш кертү турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 12 ноябрендәге 1156 номерлы карары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Масловка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл жирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл жирлеге Советының 2017 елның 04.09. №11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

Масловка авыл жирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл жирлеге Советының 2019 елның 13.08. №Х номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) II бүлекнең 50 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "каты коммуналь калдыкларны чыгару – каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарыннан (мәйданчыклардан) алып каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү өчен файдаланыла торган объектларга кадәр ташу (илтеп житкерү)";

1.2) 4.6 пунктындагы 4.6.1.7 пунктчасын төшереп калдырырга;

1.3) 4.6 пунктының 4.6.1.8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4.6.1.8. Жирлек территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү коммуналь калдыклар, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендәге төбәк программасы һәм калдыклар белән эш итүнең территориаль схемасына (алга таба – калдыклар белән эш итү схемасы) ярашлы рәвештә кулланучылар белән төзелгән каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән шартнамәләр нигезендә төбәк операторлары тарафыннан тәэмин ителә.

Төбәк операторы каты коммуналь калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшләрен мөстәкыйль рәвештә яки каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторларны җәлеп итеп башкара.

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәтләр күрсәтүгә шартнамә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 12 ноябрендәге 1156 номерлы карары белән расланган каты коммуналь калдыклар белән эш итү кагыйдәләренең I бүлегендә каралган тәртиптә кулланучы һәм эшчәнлеге зонасында каты коммуналь калдыклар барлыкка килә торган һәм аларның туплану урыннары (мәйданчыклары) булган төбәк операторы арасында төзелә.";

1.4) 4.6.4.13 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"теләсә нинди материалларны, грунт, утын, чабылган үләнне, чүп-чарны, зур габаритлы калдыкларны, төзелеш материалларын йорт биләмәсе территориясе тышында өяргә;

сүтелә (таркатыла) башлаган (төзек булмаган) транспорт чарасын йорт биләмәсе территориясе тышында сакларга".

1.5) 4.6.7.4 пунктында "саклангалык" сүзен төшереп калдырырга;

1.6) 4.7.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4.7.1. Йорт хайваннарын тотуның төп принциплары, шартлары, этләрне урамда йөртү кагыйдәләре "Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында" 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән тәгаенләнә".

2. Карар рәсми игълан ителгән (халыкка житкерелгән) көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл жирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль

районы, Масловка ав.,Центральный ур., 13 ой, һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге башлыгы

А.И. Егоров